**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«08» ноябрь, 2021 ел Новотроицк авылы № 7

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә

**КАРАР:**

1. 2021 елның 19 ноябрь 20.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу, китерү, җәю);
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;
- зиратны төзекләндерү (хуҗалык инвентаре өчен бина урнаштыру).»

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калиновка авылы, К. Маркс урамы, һәлак булган авылдашларга куелган һәйкәл янында.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (https://tukay.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Ю.М. Рыбакова